ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 567-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 567-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 6 июне
№ 2486-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗАКОНЫ

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында**

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 10 пунктына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш), «2025 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2026 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проекты оешмалар мөлкәтенә салым буенча салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен билгеләнгән ташламалы салым ставкаларының гамәлдә булуын озайтуны күздә тота.

Бакчачылык яки яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәтләренә, шулай ук бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыгы алып бару өчен гражданар тарафыннан 2019 елның 1 гыйнварына кадәр оештырылган коммерцияле булмаган оешмаларга карата гомуми файдаланудагы мөлкәт булып торучы мөлкәткә карата салым салудан азат итүне 2026 елның 1 гыйнварына кадәр озайту каралган.

Сәламәтлек саклау, физик культура һәм спорт ихтыяҗлары өчен кулланыла торган социаль-мәдәни өлкә объектларына карата оешмалар өчен, федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан финанслана торган оешмалардан тыш, халыкның медицина ярдәме сыйфатыннан канәгатьлеген арттыру һәм халыкның физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче өлешен арттыру максатыннан билгеләнгән өстенлекләрне салымны исәпләнгән салым суммасының 4,55 проценты күләмендә түләү рәвешендә 2026 елның 1 гыйнварына кадәр озайту каралган.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

## ИСЕМЛЕГЕ

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының**
**5 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итмәячәк.

Бакчачылык яки яшелчәчелек коммерцияле булмаган ширкәтләренә һәм сәламәтлек саклау, физик культура һәм спорт ихтыяҗлары өчен кулланыла торган социаль-мәдәни өлкә объектларына карата салым преференцияләре суммасы 208,7 млн сум тирәсе бәяләнә.